| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КУАКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

2023елның 30 октябрендә №4

Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 18 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авылы җирлеге Сходнево-Чертанлы авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

2.1.Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанлы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезне бүлектә укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 1000 (Бер мең) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы)юлларны кардан чистарту;
Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы) чокырлы юлларны вак таш белән ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2.2 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Сходнево-Чертанлы торак пунктында гражданнар җыенының 2018 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карары нигезендә җыелган гражданнарның үзара салым салу чараларын түбәндәгеләргә тоту белән белән килешәсезме
-Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанлы торак пунктының сууткәргеч мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлегенә ярашлы рәвештә сууткәргеч мөлкәтен тоту, тапшырылган вәкаләтләргә ярашлы рәвештә, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы) юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы К. Маркс урамындагы җирле үзидарә бинасы, 15 йорт, Сходнево-Чертанлы авылында Азатлык урамындагы авыл клубы бинасында, 5б йорт, Чуте авылында Тынычлык урамындагы авыл клубы бинасында, 8а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова